ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 06.06.2023 802 **КАРАР**

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән (алга таба-хәрби хезмәткәрләр), шулай ук махсус операция вакытында хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган гражданнарының гаиләләренә түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын расларга:

1.1. Ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түбәндәге түләүләрдән азат итәргә:

- Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында туклану, шулай ук баланы карап торганы һәм караганы өчен;
- Алабуга муниципаль районы башкарма хакимияте органнары



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

карамагындагы мәктәпләрдә, мәктәпкәчә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендәге түгәрәкләр һәм секцияләр өчен.

1.2. Гомуми белем бирү муниципаль учреждениеләрендә укучы балаларны:

- 1-4 нче сыйныф укучыларын өстәмә бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү;

- 5-11 нче сыйныф укучыларын ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү.

1.3. Бала туганнан соң 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләүне башкару.

1.4. Түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.4.1. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына:

- мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтүче мәгариф оешмаларына, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең яшь ярымга җиткән балаларына юллама бирүне;

- Алабуга муниципаль районының мәктәп яны лагерьларына сменалар туплаган саен, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең балаларын җибәрүне;

1.4.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы мөдиренә:

- Алабуга муниципаль районының һәм Татарстан Республикасының балаларны сәламәтләндерү лагерьларына сменалар туплаган саен, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең балаларын җибәрүне;

- хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына бушлай психологик ярдәм күрсәтүне;

- волонтерлар көче белән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә адреслы ярдәм оештыруны;

1.4.3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спорт үсеше секторы мөдиренә хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын Алабуга муниципаль районының спорт объектларына абонементлар буенча бушлай йөртүне;

1.4.4. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына «Иллюзион» кинотеатрында узган чараларыга хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын бушлай йөртүне.

1.5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1.5.1. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына Татарстан Республикасы шифаханәләрнә һәм профилакторияләренә заездлар туплаганда, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын җибәрүне;

1.5.2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннәндә тәрбияләнүчеләргә Алабуга муниципаль районының белем бирү оешмаларында ярдәм чараларын финанслауны.

3. Алабуга рйоны һәм Алабуга шәһәре хәрби комиссарына Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына, һәр айның 10 нчы числосына кадәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнар исемлеген булдыруны һәм җибәрүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар (Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнар) тарафыннан хәрби хезмәт үтәү чорына кагыла дип билгеләргә.

5. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргга:

- «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» 2022 елның 17 октябрендәге 1283 номерлы карары;

- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» 2022 елның 17 октябрендәге 1283 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 3 ноябрендәге 1452 номерлы карары;

- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» 2022 елның 17 октябрендәге 1283 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 7 ноябрендәге 1472 номерлы карары;

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карарына 1 нче кушымта рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз

көченә керә һәм 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00FBD291B1574C09AAA1CBD7F6C923D025
Владелец: Исланов Роман Леонидович
Действителен с 14.03.2023 до 06.06.2024



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
06.06.2023 802 номерлы
Карарына 1 нче кушымта

06.06.2023 802

Алабуга муниципаль районында махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә, бала тууга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата түләү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм бирү
Тәртибе

Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданы булган баланың ата – аналарының берсе булган гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба-бер тапкыр бирелә торган түләү) бирү процедурасын регламентташтыра:

мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучылар;

- махсус хәрби операция барышында йөкләнгән бурычларны үтәүдә контракт буенча хәрби хезмәт узучы, (мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылмаган затлар);

-махсус хәрби операция барышында йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнар.

2. Түләүне оештыру Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм норматив хокукый акт белән билгеләнә.

3. Бер тапкыр бирелә торган түләү-бер генә башкарыла.

4. бер тапкыр бирелә торган түләү - 50 мең сум күләмендә гамәлгә ашырыла.

5. Бер үк вакытта ике яки аннан да күбрәк бала туган очракта, балаларның һәрберсенә түләү бирелә.

6. Түләү бала туганнан соң бер ел эчендә мөрәҗәгать ителгән очракта башкарыла. Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә аның ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән балага түләү бирелми.

7. Бер тапкыр бирелә торган түләүне алу максатларында мөрәҗәгать итүче Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына гариза белән мөрәҗәгать итә һәм түбәндәге документларны тапшыра:

- шәхесне раслаучы документ, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН), индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС);

- махсус хәрби операциядә катнашучы белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документ (никахлашу турында таныклык, туу турында таныклык);

- махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең, Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән, әлеге гражданнар категориясенә каравын раслаучы (шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документлар) документлар. Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән, әлеге гражданнар категориясенә керүен раслаучы документ

булып, махсус хәрби операциядә катнашучыга аның махсус хәрби операциядә катнашуы хакында хәрби часть биргән белешмә тора.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН